**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА ТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОПОСЕЛКЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТИМЕРЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Чуваш Тимерлеге ав. **КАРАР**

«13» октябрь 2025 ел № 2

Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 22 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Тимерлек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 24 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Красномайский поселогы, Үзәк урамы, 6нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогында Үзәк урамда, Полевая урамнарындагы йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын уздыру өчен Красномайский поселогы халкының исемлеген бүлү тәртибен территориаль билге буенча сайлау тәртибе.

3. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Тимерлек авыл җирлегенең Красномайский поселогы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Тимерлек авыл җирлеге Красномайский поселогы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Красномайский поселогы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Тимерлек авыл җирлеге башлыгы В.И. Гаврилов